РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Совет
Елантовского сельского поселения
Нижнекамского муниципального района

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Түбән Кама муниципаль районы
Елантау авыл җирлеге
Советы

423597, Нижнекамский район,
с. Елантово, ул. Нагорная, 1г

423597, Түбән Кама районы,
Елантау авылы Нагорная урамы, 1г

тел. /факс (8555) 33-30-42, электронный адрес: Elant.Nk@tatar.ru, сайт: www. elantovskoe-sp.ru


РЕШЕНИЕ КАРАР

16.04.2021 ел № 04/08-19

Елантау авыл җирлеге Советының 2019 елның 20 декабрендәге 52-102 номерлы « Елантау авыл җирлеге бюджетыннан Түбән Кама муниципаль районы бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 9, 142.3, 142.5 статьялары, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы «Елантау авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 31 статьясы нигезендә, Елантау авыл җирлеге Советы карар бирә:

1. Елантау авыл җирлеге Советының 2019 елның 20 декабрендәге 52-102 номерлы «Елантау авыл җирлеге бюджетыннан Түбән Кама муниципаль районы бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында» карарына (алга таба – карар) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1 Карарның исемендә «Елантау авыл җирлеге» сүзләреннән соң «субсидияләр һәм» сүзләрен өстәргә.

1.2 Карарның 1 пунктында «Елантау авыл җирлеге» сүзләреннән соң «субсидияләр һәм» сүзләрен өстәргә, «(кушымта)» сүзен «(1 нче кушымта)» сүзләренә алмаштырырга.

1.3 Карарны түбәндәге эчтәлекле 1.1 пунктча белән тулыландырырга:

«1.1 «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Елантау авыл җирлеге бюджетыннан Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы бюджетына бирелә торган субсидияләр күләмен исәплләү методикасын расларга».

1.4 Карар белән расланган Елантау авыл җирлеге бюджетыннан Түбән Кама муниципаль районы бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибендә:

нумерация исемендә «Кушымта» сүзен «1 нче кушымта» сүзләренә алмаштырырга;

исемендә «Елантау авыл җирлегенең» сүзләреннән соң «субсидияләр һәм» сүзләрен өстәргә;

1 бүлектә «Елантау авыл җирлегенең» сүзләреннән соң «субсидияләр һәм» сүзләрен өстәргә, «бирү» сүзен «субсидияләр һәм» сүзләреннән соң өстәргә;

2 бүлекнең 1 абзацында «башка бюджетара» сүзләрен «субсидияләр һәм башка бюджетара» сүзләренә алмаштырырга;

3 бүлекнең исемендә «бирү» сүзен «субсидияләр һәм» сүзләреннән соң өстәргә;

3 бүлекнең 1 пунктында «бюджетара трансфертлар» сүзләрен «субсидияләр һәм бюджетара трансфертлар» сүзләренә алмаштырырга;

3 бүлекнең 3 пунктында «бүлү» сүзен «субсидияләр һәм» сүзләреннән соң өстәргә;

3 бүлекнең 4 пунктында «бирү тәртибе» сүзләрен «субсидияләр һәм» сүзләреннән соң өстәргә;

3 бүлекнең 5 пунктында «бюджетара трансфертлар» сүзләрен «субсидияләр» сүзләренә алмаштырырга;

3 бүлекнең 6 пунктында «бюджетара трансфертлар бирү» сүзләрен «субсидияләр һәм бюджетара трансфертлар бирү» сүзләренә алмаштырырга;

3 бүлекнең 8 пунктында «бирүдә» сүзен «субсидияләр һәм» сүзләреннән соң өстәргә;

4 бүлекнең исемендә «файдаланудан» сүзен «субсидияләр һәм» сүзләреннән соң өстәргә;

4 бүлекнең 3 пунктындагы беренче җөмләдә «файдаланудан» сүзен «субсидияләр һәм» сүзләреннән соң өстәргә;

4 бүлекнең 4 пунктында «рәвешендә бирелгән» сүзләрен «субсидияләр һәм» сүзләреннән соң өстәргә;

4 бүлекнең 5 пунктында «максатсыз файдаланган өчен» сүзләрен «субсидияләр һәм» сүзләреннән соң өстәргә.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Елантау авыл җирлеге
башлыгы В.А. Лебедев

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Елантау авыл җирлеге бюджетыннан Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы бюджетына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында бирелә торган субсидияләр күләмен исәпләү методикасы

1. Елантау авыл җирлеге бюджетыннан Түбән Кама муниципаль районы бюджетына субсидияләр күләме, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында, түбәндәге формула буенча билгеләнә:

S= (Д1+Д2) - (Р+С)

кайда:

S – Елантау авыл җирлеге бюджетыннан Түбән Кама муниципаль районы бюджетына бирелә торган субсидия күләме;

Д1 – Елантау авыл җирлегенең Россия Федерациясе Бюджет законнары, салымнар һәм җыемнар турындагы законнар һәм башка мәҗбүри түләүләр турындагы законнар нигезендә беркетелгән салым һәм салым булмаган керемнәре;

Д2 – Түбән Кама муниципаль районы бюджетыннан түләүсез керемнәр;

Р – Елантау авыл җирлеге бюджетының Түбән Кама муниципаль районының берләштерелгән бюджетын формалаштыруга бердәм төп алымнар нигезендә формалаштырылган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә чыгымнары;

С – Россия Федерациясе субъекты бюджеты турында Россия Федерациясе субъекты законы нигезендә Елантау авыл җирлеге бюджетыннан Россия Федерациясе субъекты бюджетына күчерелергә тиешле субсидияләр.

2. Елантау авыл җирлеге бюджетыннан Түбән Кама муниципаль районы бюджетына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында бирелә торган субсидияләрне исәпләү тәртибе

Субсидия күләме, Елантау авыл җирлеге чыгымнарын алганнан соң, Елантау авыл җирлеге кереме буларак исәпләнә.